**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О Порядке рассмотрения ходатайств о награждении медалями Республики Татарстан «Родительская доблесть», «Ана даны – Материнская слава» и о единовременном денежном вознаграждении лицам, награжденным медалями Республики Татарстан «Родительская доблесть», «Ана даны – Материнская слава»

В соответствии с частью 1 статьи 17 и частью 2 статьи 37 Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 74-ЗРТ «О государственных наградах Республики Татарстан» **постановляю**:

1. Утвердить прилагаемый Порядок рассмотрения ходатайств о награждении медалями Республики Татарстан «Родительская доблесть», «Ана даны – Материнская слава».

2. Установить, что:

а) выплата единовременного денежного вознаграждения обеспечивается Министерством труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан в течение 30 календарных дней со дня издания указа о награждении медалью Республики Татарстан «Родительская доблесть» или медалью Республики Татарстан «Ана даны – Материнская слава» в следующих размерах:

родителям (усыновителям), награжденным медалью Республики Татарстан «Родительская доблесть», – 100 тысяч рублей. Единовременное денежное вознаграждение выплачивается одному из родителей (усыновителей), награжденных медалью Республики Татарстан «Родительская доблесть»;

матерям, награжденным медалью Республики Татарстан «Ана даны – Материнская слава», воспитавшим пять детей, – 50 тысяч рублей;

матерям, награжденным медалью Республики Татарстан «Ана даны – Материнская слава», воспитавшим шесть и более детей, – размер единовременного денежного вознаграждения увеличивается соответственно на 10 тысяч рублей из расчета на шестого и каждого последующего ребенка, при условии достижения ими на день награждения возраста трех лет;

б) в случае смерти награжденного, которому при жизни единовременное денежное вознаграждение не было выплачено, единовременное денежное вознаграждение передается по наследству в порядке, установленном законодательством Российской Федерации.

3. Кабинету Министров Республики Татарстан обеспечить в установленном порядке финансирование расходов, связанных с реализацией настоящего Указа.

4. Внести в абзац второй пункта 1 Порядка рассмотрения ходатайств о награждении государственными наградами Республики Татарстан, утвержденного Указом Президента Республики Татарстан от 27 декабря 2011 года № УП-875 «О рассмотрении ходатайств о награждении государственными наградами Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 12 августа 2016 года № УП-684, от 16 апреля 2020 года № УП-231 и от 11 августа 2020 года № УП-475), изменение, изложив его в следующей редакции:

«Действие настоящего Порядка не распространяется на отношения, связанные с рассмотрением ходатайств о награждении государственными наградами Республики Татарстан – медалями «Родительская доблесть», «Ана даны – Материнская слава».».

5. Внести в пункт 6 Положения о порядке вручения государственных наград Республики Татарстан, утвержденного Указом Президента Республики Татарстан от 13 июня 2018 года № УП-424 «Об утверждении Положения о порядке вручения государственных наград Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными Указом Президента Республики Татарстан от 16 апреля 2020 года № УП-231), следующие изменения:

а) дополнить новым абзацем восьмым следующего содержания:

«медаль «Родительская доблесть»;»;

б) абзацы восьмой – пятнадцатый считать соответственно абзацами девятым – шестнадцатым.

6. Признать утратившими силу:

Указ Президента Республики Татарстан от 2 ноября 2000 года № УП-828 «О порядке рассмотрения и представления документов к награждению медалью Республики Татарстан «Ана даны – Материнская слава»;

Указ Президента Республики Татарстан от 23 июля 2004 года № УП-494 «О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О порядке рассмотрения и представления документов к награждению медалью Республики Татарстан «Ана даны – Материнская слава»;

Указ Президента Республики Татарстан от 27 февраля 2009 года № УП-106 «О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О порядке рассмотрения и представления документов к награждению медалью Республики Татарстан «Ана даны – Материнская слава»;

пункт 2 Указа Президента Республики Татарстан от 22 июня 2010 года № УП-397 «Об утверждении описания государственной награды Республики Татарстан – медали «Ана даны – Материнская слава», формы (образца) удостоверения к ней и формы наградного листа»;

пункт 1 Указа Президента Республики Татарстан от 27 декабря 2011 года № УП-876 «О внесении изменений в отдельные указы Президента Республики Татарстан по вопросам награждения медалью Республики Татарстан «Ана даны – Материнская слава»;

Указ Президента Республики Татарстан от 14 марта 2018 года № УП-232 «О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О порядке рассмотрения ходатайств о награждении медалью Республики Татарстан «Ана даны – Материнская слава».

7. Настоящий Указ вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

**Президент Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
15 апреля 2022 года
№ УП-284

Утвержден
Указом Президента
Республики Татарстан

от «15» апреля 2022 года

№ УП-284

**Порядок**
**рассмотрения ходатайств о награждении медалями Республики Татарстан «Родительская доблесть», «Ана даны – Материнская слава»**

1. Настоящим Порядком определяется процедура рассмотрения ходатайств о награждении медалями Республики Татарстан «Родительская доблесть», «Ана даны – Материнская слава» (далее соответственно – ходатайство, медаль), а также перечень документов и сведений, прилагаемых к ходатайству.

2. Ходатайства возбуждаются коллективами организаций, общественными объединениями, государственными органами, органами местного самоуправления в Республике Татарстан.

3. При возбуждении ходатайства заполняется наградной лист по форме, утвержденной Президентом Республики Татарстан.

Лица, оформляющие и подписывающие наградной лист, обеспечивают достоверность указанных в нем сведений.

4. Ходатайство с приложением документов и сведений, указанных в приложении к настоящему Порядку, наградного листа (далее – наградные документы) вносится в государственные органы (должностным лицам), которые в соответствии со статьей 19 Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 74-ЗРТ «О государственных наградах Республики Татарстан» обладают правом на представление к награждению государственными наградами Республики Татарстан (далее – органы, уполномоченные вносить представления).

Внесение ходатайства и наградных документов в органы, уполномоченные вносить представления, осуществляется коллективами организаций, общественными объединениями, государственными органами и органами местного самоуправления в Республике Татарстан, возбудившими ходатайство.

5. Органы, уполномоченные вносить представления, рассматривают ходатайство и наградные документы в течение 30 календарных дней со дня их регистрации.

6. В представлении к награждению медалью отказывается в случаях:

выявления несоответствия лиц, в отношении которых возбуждено ходатайство, требованиям, предъявляемым законодательством

о государственных наградах Республики Татарстан к лицам, которые могут быть удостоены медали;

возникновения оснований, предусмотренных статьей 21 Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 74-ЗРТ «О государственных наградах Республики Татарстан»;

внесения ходатайства в орган, уполномоченный вносить представления, который не обладает правом на представление к медали соответствующих категорий граждан;

внесения ходатайства без наградных документов, которые предусмотрены настоящим Порядком.

7. Об отказе в представлении к награждению медалью составляется мотивированное заключение, которое вместе с внесенным ходатайством и приложенными к нему наградными документами направляется коллективу организации, в общественное объединение, государственный орган, орган местного самоуправления в Республике Татарстан, которые внесли ходатайство.

В случае устранения причин отказа в представлении к награждению медалью ходатайство и наградные документы могут быть внесены повторно.

8. Представление к награждению медалью вносится Президенту Республики Татарстан с приложением ходатайства и наградных документов.

Приложение
к Порядку рассмотрения
ходатайств о награждении
медалями Республики Татарстан
«Родительская доблесть»,
«Ана даны – Материнская слава»

**Перечень**
**документов* и сведений, прилагаемых к ходатайству о награждении медалями Республики Татарстан «Родительская доблесть», «Ана даны – Материнская слава»**

1. Заверенная копия паспорта родителей (усыновителей) (одного из родителей (усыновителей)**).

2. Заверенные копии свидетельств о рождении детей.

3. Заверенная копия свидетельства о браке (при его наличии).

4. Документы, подтверждающие факт смены фамилии, имени, отчества родителей (усыновителей) и их детей (при наличии таких фактов).

5. Справки воинских частей или военных комиссариатов – на детей, находящихся на военной службе.

6. Документы (в том числе справки воинских частей, военных комиссариатов), подтверждающие обстоятельства гибели, пропажи без вести, смерти детей, указанные в части 4 статьи $10^1$ и в пункте 2 части 4 статьи 11 Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 74-ЗРТ «О государственных наградах Республики Татарстан» (при наличии таких обстоятельств).

7. В случае смерти одного из родителей (усыновителей), ребенка (детей) – копия свидетельства о смерти.

8. Характеристики на семью и родителей (усыновителей) (одного из родителей (усыновителей)**).

9. Справки с места учебы, работы детей и родителей (усыновителей) (одного из родителей (усыновителей)**).

10. Справка об отсутствии у родителей (усыновителей) (одного из родителей (усыновителей)**) задолженности по налогам, сборам и иным обязательным платежам в бюджеты бюджетной системы Российской Федерации.

11. Заключения органов управления образованием, здравоохранением, органов записи актов гражданского состояния, территориальных органов социальной защиты, территориальных органов внутренних дел и комиссии по делам несовершеннолетних, образуемой в соответствующем муниципальном районе (городском округе) Республики Татарстан, содержащие сведения об отношении родителей (усыновителей) (одного из родителей (усыновителей)**) к воспитанию своих детей.

12. Документы, подтверждающие социальную активность родителей (усыновителей) (одного из родителей (усыновителей)**) и их детей (дипломы, грамоты, свидетельства и другие документы об участии в общественных мероприятиях), публикации о семье в средствах массовой информации (при наличии).

13. Заключение*** главы муниципального района (городского округа) Республики Татарстан по месту жительства родителей (усыновителей) (одного из родителей (усыновителей)**).

14. Заключения*** Министерства труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан, Министерства образования и науки Республики Татарстан, Управления записи актов гражданского состояния Кабинета Министров Республики Татарстан, Республиканской комиссии по делам несовершеннолетних и защите их прав.

15. Реквизиты расчетного счета, открытого в кредитной организации Российской Федерации, для получения единовременного денежного вознаграждения.

---

Примечания:

* Документы, перечисленные в пунктах 5, 8–11, 13, 14 настоящего Перечня, считаются действительными в течение года.

** В случае смерти одного из родителей (усыновителей) или награждения матери медалью Республики Татарстан «Ана даны – Материнская слава».

*** Заключение готовится на основании ходатайства о награждении медалью Республики Татарстан «Родительская доблесть» или медалью Республики Татарстан «Ана даны – Материнская слава», наградного листа, документов и сведений, предусмотренных пунктами 1–12 настоящего Перечня, в течение 30 календарных дней со дня их регистрации.

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге», «Ана даны – Материнская слава» медальләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибе хакында һәм Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге», «Ана даны – Материнская слава» медальләре белән бүләкләнгән затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк хакында**

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы 1 кисәгe һәм 37 статьясы 2 кисәгe нигезендә **карар бирәм:**

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге», «Ана даны – Материнская слава» медальләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибен расларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге» яисә Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медальләре белән бүләкләү турында указ чыккан көннән алып 30 көн дәвамында түбәндәге күләмнәрдә бирелә:

Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге» медале белән бүләкләнгән ата-аналарга (уллыкка яки кызлыкка алучыларга) – 100 мең сум. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге» медале белән бүләкләнгән ата-аналарның (уллыкка яки кызлыкка алучыларның) берсенә түләнә;

Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләнгән, биш бала тәрбияләп үстергән аналарга – 50 мең сум;

Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләнгән, алты яисә аннан күбрәк бала тәрбияләп үстергән аналарга – бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк күләме алтынчы балага һәм аннан соң килә торган һәр балага хисаплап, бүләкләү көненә аларның өч яше тулган булу шарты үтәлгәндә, тиешенчә 10 мең сумга арта;

б) бүләкләнгән зат вафат булган очракта, әгәр аңа бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк тапшырылмаган булса, бер тапкыр бирелә торган

акчалата бүләк Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мирас буларак тапшырыла.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау хакында» 2011 елның 27 декабрендәге ПУ-875 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 12 августындагы ПУ-684 номерлы, 2020 елның 16 апрелендәге ПУ-231 номерлы һәм 2020 елның 11 августындагы ПУ-475 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибенең 1 пунктындагы икенче абзацка, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Әлеге Тәртипнең гамәле Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре – «Ата-ана фидакарьлеге», «Ана даны – Материнская слава» медальләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау белән бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.».

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 13 июнендәге ПУ-424 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2020 елның 16 апрелендәге ПУ-231 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру тәртибе турында нигезләмәнең 6 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац өстәргә:

«Ата-ана фидакарьлеге» медале;»;

б) сигезенче – унбишенче абзацларны тиешенчә тугызынчы – уналтынчы абзацлар дип санарга.

6. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибе турында» 2000 елның 2 ноябрендәге ПУ-828 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 23 июлендәге ПУ-494 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 27 февралендәге ПУ-106 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләге – «Ана даны – Материнская слава» медале тасвирламасын, аңа таныклык формасын (үрнәген) һәм бүләкләү кәгазе формасын раслау турында» 2010 елның 22 июнендәге ПУ-397 номерлы Указының 2 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 27 декабрендәге ПУ-876 номерлы Указының 1 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 14 мартындагы ПУ-232 номерлы Указы.

7. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән 10 көн узганнан соң үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 15 апрель
№ ПУ-284

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның «15» апрелендәге
ПУ-284 номерлы Указы
белән расланды

**Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге», «Ана даны – Материнская слава» медальләре белән**
**белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау**
**тәртибе**

1. Әлеге Тәртип нигезендә Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге», «Ана даны – Материнская слава» медальләре белән бүләкләү турында үтенечнамәләрне (алга таба тиешенчә – үтенечнамә, медаль), шулай ук үтенечнамәгә кушымта итеп бирелүче документлар һәм белешмәләрне карау процедурасы билгеләнә.

2. Үтенечнамәләр оешмалар коллективлары, җәмәгать берләшмәләре, дәүләт органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары тарафыннан кузгатыла.

3. Үтенечнамә кузгатылганда, Татарстан Республикасы Президенты раслаган форма буенча бүләкләү кәгазе тутырыла.

Бүләкләү кәгазен рәсмиләштерүче һәм аңа кул куючы затлар анда күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеген тәэмин итә.

4. Әлеге Тәртипкә кушымтада күрсәтелгән документлар теркәп бирелгән үтенечнамә һәм бүләкләү кәгазе (алга таба – бүләкләү документлары) «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 19 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдим итү хокукы булган дәүләт органнарына (вазыйфаи затларга) (алга таба – бүләкләүгә тәкъдим итәргә вәкаләтле органнар) җибәрелә.

Бүләкләүгә тәкъдим итәргә вәкаләтле органнарга үтенечнамәне һәм бүләкләү документлары оешмалар коллективлары, җәмәгать оешмалары, дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырыла.

5. Бүләкләүгә тәкъдим итәргә вәкаләтле органнар үтенечнамәне һәм бүләкләү документларын аларны теркәгән көннән соң 30 календарь көн эчендә карый.

6. Медаль белән бүләкләүгә тәкъдим итүдән түбәндәге очракларда баш тартыла:

аларга карата үтенечнамә кузгатылган затларның Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында законнарда Татарстан

Республикасы дәүләт бүләкләренә лаек булырга мөмкин затларга куелган таләпләргә туры килмәве ачыкланганда;

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясында каралган нигезләр барлыкка килгәндә;

әлеге үтенечнамә тиешле категория гражданнарны Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә тәкъдим итү хокукы булмаган дәүләт органына бирелгәндә;

үтенечнамә әлеге Тәртиптә каралган документлардан башка бирелгәндә.

7. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдим итүдән баш тарту турында сәбәпләре күрсәтелгән бәяләмә тутырыла, ул бирелгән үтенечнамә һәм аңа теркәп бирелгән бүләкләү документлары белән бергә үтенечнамәне кузгаткан оешма коллективына, җәмәгать берләшмәсенә, дәүләт органына, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органына җибәрелә.

Медаль белән бүләкләүгә тәкъдим итүдән баш тарту сәбәбе бетерелгән очракта, үтенечнамә һәм бүләкләү документлары кабат бирелергә мөмкин.

8. Медаль белән бүләкләүгә тәкъдим итү үтенечнамә һәм бүләкләү документлары белән бергә Татарстан Республикасы Президентына бирелә.

Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге», «Ана даны – Материнская слава» медальләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибенә кушымта

**Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге», «Ана даны – Материнская слава» медальләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләргә теркәп бирелә торган документлар* һәм белешмәләр исемлеге**

1. Ата-ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының) (атаның яисә ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының**) паспортының расланган күчермәсе.

2. Балаларның туу таныклыгының расланган күчермәсе.

3. Никахлашу турындагы таныклыкның (булган очракта) расланган күчермәсе.

4. Ата-аналарның (уллыкка яки кызлыкка алучыларның) һәм балаларының фамилиясен, исемен, атасының исемен алыштыру фактын (андый фактлар булган очракта) раслаучы документлар.

5. Хәрби частьләр һәм хәрби комиссариатларның хәрби хезмәттәге балаларга кагылышлы белешмәләре.

6. Балаларның һәлак булуының, хәбәрсез югалуының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясының 4 кисәгендә һәм 11 статьяның 4 кисәгендәге 2 пунктта күрсәтелгән шартларын (андый шартлар булганда) раслаучы документлар (шул исәптән хәрби частьләр, хәрби комиссариатлар белешмәләре).

7. Ата яисә ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының), баланың (балаларның) вафат булуы очрагында – вафат булу турында белешмәнең күчермәсе.

8. Гаиләгә һәм ата-анага (уллыкка яки кызлыкка алучыга) (атага яисә анага (уллыкка яки кызлыкка алучыга**) характеристикалар.

9. Балаларның һәм ата-ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының) (атаның яисә ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының**) уку, эш урыныннан белешмәләр.

10. Ата-ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының) (атаның яисә ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының**) салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри башка түләүләр буенча бурычлары булмау турында белешмә.

11. Белем бирүгә, сәламәтлек саклауга идарә итү органнарының, граждан хәле актларын теркәү органнарының, территориаль социаль яклау органнарының, территориаль эчке эшләр органнарының һәм Татарстан

органнарының, территориаль эчке эшләр органнарының һәм Татарстан Республикасының тиешле муниципаль районында (шәһәр округында) төзелгән балигъ булмаганнар эшләре комиссиясенең ата-ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының) (атаның яисә ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының**) балаларын тәрбияләүгә мөнәсәбәте турындагы белешмәләр бирелгән бәяләмәләре.

12. Ата-ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының) (атаның яисә ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының**) һәм аларның балаларының социаль активлыгын раслаучы документлар (дипломнар, грамоталар, иҗтимагый чараларда катнашу турында таныклыклар һәм башка документлар), гаилә турында массакүләм мәгълүмат чараларында басмалар (булган очракта).

13. Ата-ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының) (атаның яисә ананың (уллыкка яки кызлыкка алучының**) яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгының бәяләмәсе***.

14. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенең, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең бәяләмәләре***.

15. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне алу өчен Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счеты реквизитлары.

---

Искәрмәләр:

* Әлеге Исемлекнең 5, 8–11, 13, 14 пунктларында санап кителгән документлар бер ел дәвамында гамәлдә дип санала.

** Ата яисә ана (уллыкка яки кызлыкка алучы) вафат булган яисә ана Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләнгән очракта.

*** Бәяләмә Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге» медале яисә Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү турында үтенечнамә, бүләкләү кәгазе, әлеге Исемлекнең 1–12 пунктларында күрсәтелгән документлар һәм мәгълүматлар нигезендә алар теркәлгән көннән соң 30 календарь көн дәвамында әзерләнә.